СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**30 апрель 2019 ел**

**КАРАР**
**№ 152**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Рәсәй Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм Балтач муниципаль районы прокуратурасының 20.02.2019 елдан № 02-01-22-2019 мәгълүмати хаты, Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 декабрендәге 137 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәнең 2.25 пунктында «киңлеге» сүзе алдыннан гомуми файдалану" дигән сүзтезмә өстәргә»;

1.2. Кагыйдәнең 2.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

"2.2. Төзекләндерү элементлары-декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр.»

1.3. 3.1 пунктында «вакытлы корылмалар» дигән сүзтезмәләрдән соң «территорияне чүп үлән һәм куак үсемлекләре басып алуы, барыннан да элек, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы үсемлекләр (шул исәптән Сосновский балтырганы)» дип өстәргә.

2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Чепья авыл
җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　А.Г. Нотфуллин